СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

14.08.2023 ел Баулы шәһәре 209

“Баулы муниципаль районы муниципаль милкендә
булган, өченче зат хокукыннан азат булган һәм
кече һәм урта эшкуарлык субъектларына милек итеп
һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт
исемлеген раслау турында” 2020 елның 3 апрелендәге
256 номерлы Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы Советы карарына
үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 14 статьясына, 2007 елың 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү” Федераль законның 18 статьясына, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставының 73 статьясына ярашлы Баулы муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

2023 елның 3 апрелендәге 256 номерлы Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы карары белән (2020 елның 23 октябрендәге 14 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, Баулы муниципаль районы муниципаль милкендә булган, өченче зат хокукыннан азат булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына милек итеп һәм (яки) озак вакытлы файдалануга (шул исәптән аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча) тапшыру максатында, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын формалаштыручы оешмаларга, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектлары милкенә түләүле нигездә читләштерү максатларында, мөлкәт исемлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

кушымтаның 14 пунктын төшереп калдырырга;

кушымтаның 15 пунктын 14 пункт дип танырга;

15 пункт белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 15. | Җир кишәрлеге | 535 594,00 | Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы Александровка авыл җирлеге 16:11:000000:2362 | Баулы муниципаль районы |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Советының икътисади үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес, торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы
район Советы Рәисе И.И. Гозәеров